**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**2021-2022 учебный год**
**9 класс**

**I. Гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз / Напишите татарский вариант речевых реплик** (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

1) Что мне делать?
2) Так нельзя
3) Неужели?
4) Браво!
5) Подождите немного
6) Что случилось?
7) Совершенно верно!
8) Будьте внимательны!
9) Конечно!
10) Превосходно!

***II.*** **Хәрефләрне дөрес тәртиптә урнаштырып, сүзләрне табыгыз. Алардан мәкаль төзегез. /** Составьте из букв слова. Найдите пословицу**.** (10 баллов. *За нахождение слов 5 баллов, за составление пословицы 5 баллов).*

*РЫККЫ БСӘМИРЕШ РБЕ УКМ БЫЛЫШЫ АААГДНН*

***III.*** **Сүзтезмәләрнең һәр элементын антонимнары белән алыштырып языгыз. /** Замените каждый элемент словосочетаний антонимами (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу*).

Төньякка бару; кышын табу; кичәгедән соң оныту; акка пычрату; соң кайту; сиңа җавап бирү; урамга китү; кичен белү; болытлы көн; җылы керү.

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).

Үз җыры бар башкаручылар азая бау сәбәпле, эстрадада үзгәрешләр сизелә. (ВМ)

**V. Тексттан гарәп-фарсы алынма тамырлы сүзләрне язып алыгыз. /** Выпишите из текста слова с арабо-персидскими корнями. (10 баллов, по 1 баллу за каждый правильный пример)

Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. Кәүсәсенә еллар бөҗрасы өстәлгән саен, аның хәтере дә байый баруын кешеләр беләләр микән? Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. Аның иң беренче теләге бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. Янәшәдә генә – сиртмәле кое. Арырак – салам түбәле өй. Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. Янәшәдә генә салкын җир дымын, шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. Аның тизрәк үсәсе һәм ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)

**VI. Татар телендә килешләрнең вазифасы турында языгыз. Мисаллар белән аңлатыгыз. /** Напишите о функциях падежей в татарском языке. Приведите примеры**.** (15

баллов. За описание каждого падежа по 2 *балла. +3 балла за описание грамматической категории*).

**VII. Түбәндәге морфологик таләпләргә туры килгән сүзләрдән торган җөмлә төзеп языгыз. /** Напишите предложение, слова в которого соответствуют следующим морфологическим требованиям. (10 баллов. Каждое слово оценивается 1 *баллом*).

1 нче сүз – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;
2 нче сүз – исемләшкән сыйфат фигыль, үткән заманда **,** урын-вакыт килешендә;
3 нче сүз – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;
4 нче сүз – бәйлек сүз, 3 зат берлектәге тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә;
5 нче сүз – рәвеш, күләм-чама рәвеше.
6 нчы сүз – кисәкчә,
7 нче сүз – сыйфат, асыл сыйфат, гади дәрәҗәдә.
8 нче сүз – билгесезлек алмашлыгы.
9 нчы сүз – исем сүз төркеме, ясалма, баш килештә, берлек санда;
10 нчы сүз – хикәя фигыль, билгеле үткән заманда, өченче затта, берлек санда, барлыкта.

**VIII. «Кояш - чыгышта, кош - очышта, кеше юмартлыкта матур. (Мөсәгыйт Хәбибуллин» канатлы сүзен сез ничек аңлыйсыз? Шушы гыйбарәдә әйтелгән фикергә таянып, 80 сүздән артмаган инша языгыз. /«Солце - на заре, птица - во взлёте, человек в доброте красивы» (Мусагит Хабибуллин)** Напишите, как вы понимаете данный афоризм? Опираясь на это выражение, напишите сочинение (не более из 80 слов) (20 баллов).